**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Яңа Кади авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең Утыз Имән торак пунктында

**20.10.2023 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең Утыз Имән торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең Утыз Имән торак пнкты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 550 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Утыз Имән торак пунктында «Чәчәкле алан» чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алуга;

- Утыз Имән торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Утыз Имән торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, триммерлар сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Утыз Имән торак пунктында Совет урамындагы 25 метрлы, Киров урамындагы 35 метрлы һәм Дзержинский урамындагы 150 метрлы урам-юл челтәрен төзекләндерү (40-70 мм фракциясендәге вак ташлар сатып алу);

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы М.М.Әминов